ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АПАЗОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Советская, д. 18, с.Апазово,
Арский муниципальный район, 422006

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АПАЗ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Совет урамы, 18 йорт, Апаз авылы,
Арча муниципаль районы, 422006

Тел. (84366)94-2-37, факс (84366)94-2-37. E-mail: Apaz.Ars@tatar.ru

# КАРАР

**« 22 » сентябрь 2017 ел** **№ 17**

**Референдум уздыру буенча инициатива күрсәтү турында**

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Апаз авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирде:

1. Җирле референдум уздыруны түбәндәге сорау буенча тәкъдим итәргә:

«2018 елда Апаз авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 380 сум күләмендә (түләү күләме 190 сум тәшкил иткән укуның көндезге формасында укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан, 70 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш,) үзара салым акчасы җыю һәм аны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл иту гә җибәрү белән килешәсезме?

| | Җирле әһәмияттәге мәсьәләнең аталышы | Планлаштырылган чаралар |
|---|---|---|
| 1 | Җирлек территориясендә төзекләндерү эшләрен оештыру | Хәсәншәех авылында урам утларын карап тоту һәм ремонтлау |
| 2 | Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге | -вак таш сатып алу, юл-урам челтәрендәге вак таш һәм юл өслеген төзекләндерү буенча хезмәтләр күрсәтү:<br>Апаз авылы<br>Тукай урамы (3-нче йорттан 14-нче йортка кадәр, Совет урамы, 49-нчы йорт янындагы тыкрык белән |

| | | |
|---|---|---|
| | | (370 м) (вак таш),<br>Базар урамы (21нче йорттан 45 нче йортка кадәр (380 м) (вак таш),<br>Гагарин ур., 32 йорттан 46 йортка кадәр, янәшәдәге юл белән Совет ур., 18а (балалар бакчасы) (420 м) (вак таш)<br><br>Каратай авылы (Каратай авылына килү юлы) (вак таш)<br><br>Пөшәңгәр авылы<br>Әһлиуллин урамы (1 нче йорттан 7 нче йортка кадәр (120 м) (вак таш)<br>- нигез салу : Нагорная урамы (1нче йорттан 35 нче йортка кадәр) (чуерташ)<br><br>Миржәм авылы Н. Сафин урамы (12-нче йорттан 23-нче йортка кадәр) (вак таш)<br><br>Кзыл-Игенче авылы, Дальняя урамы (5-нче йорттан 6-нчы йортка кадәр) (вак таш) |
| 3 | Күмү урыннарын карап тоту һәм ритуаль хезмәтләр оештыру | -торак пунктлардагы зиратларны карап тоту өчен инструментлар (бензопила, чапкыч) сатып алу:<br>Апаз авылы<br>Каратай авылы<br>Пөшәңгәр авылы<br>Миржәм авылы<br>Хәсәншәех авылы<br><br>- Хәсәншәех авылында җирләү өчен кирәк-яраклар алу<br>- Хәсәншәех авылы зираты территориясендә агачларны санитар кисү |
| 4 | Җирлек территориясендә төзекләндерү эшләрен оештыру | торак пунктларда аншлаглар әзерләү һәм урнаштыру:<br>Апаз авылы<br>Хәсәншәех авылы<br>Миржәм авылы |

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

Әйе　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　юк

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) яисә Арча муниципаль районының рәсми сайтында һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында урнаштырырга: Татарстан Республикасы, Арча районы, Апаз авылы, Совет урамы, 19 йорт; Татарстан Республикасы, Арча районы, Хәсәншәех авылы, Космонавтлар урамы, 20 йорт; Татарстан Республикасы, Арча районы, Пөшәңгәр авылы, Чапаев урамы, 42А йорты, Чапаев урамы, 33 йорт; Татарстан Республикасы, Арча районы, Миржәм авылы, Н.Сафин урамы, 36 йорт.

Апаз авыл җирлеге башлыгы — Р.Ш.Садиков

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН "АРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН" • ОГРН 1061685005689
МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ "АПАЗОВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ"
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АПАЗОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1609009805